РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«НОВОЧЕРШИЛИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ
ПОСЕЛЕНИЕ»

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
«ЯНА ЧЫРШЫЛЫ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

№ 29　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　2022 елның «2» ноябре

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2021 елның 17 декабрендәге «2022 елга һәм 2023 һәм 2024 елларның план чорына бюджеты турында» 33 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2021 елның 17 декабрендәге «2022 елга һәм 2023 һәм 2024 елларның план чорына бюджеты турында» 33 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1. 1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:
«2022 елга бюджетның төп характеристикаларын расларга:
1) «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 21158118,69 сум;
2) «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 1668124,44 сум».

2. 2022 елга «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.
3. «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетында 2022 елга керем күләмен әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.
4. «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.
5. «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм төркемнәре буенча әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә расларга.
6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Яңа Чыршылы поселогы, Заречная, 25 йорт, Центральная, 12А йорты адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль

районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

7.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Яңа Чыршылы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
башлык урынбасары

Р.С.Минһаҗев